| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 01 » сентябрь 2021 ел № 273

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча комиссия төзү турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, «Татарстан Республикасы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча комиссия төзү турында» 2017 елның 11 июлендәге 473 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нтгезендә, шулай ук хәрби бәрелешләр вакытында яисә шушы бәрелешләр аркасында, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә халыкның исән калу өчен кирәкле оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча комиссияне төзергә.

2. 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча комиссия турында нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының

рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов